Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ 26

КАРАР
18.12.2024

Чәчәкле авыл җирлегендә Фейерверклар үткәрү
өчен мәйданчыкны билгеләү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, "Янгын куркынычсызлыгы турында" 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы, "Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент" 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 22 декабрендәге 1052 номерлы карары нигезендә пиротехник әйберләрне таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында" 2009 елның 22 декабрендәге 1052 номерлы карары нигезендә, петардны ирексез яисә алдан ниятләп шартлау максатыннан, шулай ук Чәчәкле авыл җирлегендә пиротехника продукциясен детонацияләү турында карары :

1.Чәчәкле авыл җирлегендә яшәүчеләр һәм кунаклар очен фейерверклар уздыру мәйданчыкларны - территорияне, билгеләргә.

**Чәчәкле авылы** - Үрдәк елгасының яр буе зонасы, А.Алиш, Д.Гатауллин, М.Җәлил, Г.Тукай урамнары буйлап йортлардан 100 метр ераклыкта;

**Йолдыз авылы** - Үрдәк елгасының яр буе зонасы, Садовая урамы, Зеленая урамы, йортлардан 100 метр ераклыкта.

2. Татарстан Республикасы Әлки һәм Спас МР буенча УНД һәм Россия ГТХМның Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең районара бүлеге белән фейерверклар үткәрү мәйданчыгын килештерергә.

3. Халыкны пиротехник чаралар (эшләнмәләр) куллану өчен төзелгән мәйданчыклар турында мәгълүматлаштырырга һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Чәчәкле авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыруны оештырырга.

4. Гражданнарның хуҗасыз төзелешләргә, коллекторларга һәм торак йортларның подвалларына керүен чикләү чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләсен карарга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Чәчәкле авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Фәисханов